**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№132** **27.05.2019 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе турында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.И. Нуриев**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең 2019 елның 27 маендагы 132 номерлы карарына 1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советына язмача түбәндәге адреска бирелә: 423536, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Бохарай авылы, Новая урамы, 4 нче йорт.
Бу турыда халыкка җиткерелгәннән соң тәкъдимнәр эш көннәрендә иртәнге сәгать 8 дән кичке 4 кә кадәр кабул ителә.
2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 423536, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Бохарай авылы, Новая урамы, 4 йорт адресы буенча кабул ителә яки почта аша җибәрелә (Конвертта «Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты турында фикер алышу» дигән тамга белән).